ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары турында» 2004 елның 15 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның беренче өлешендә:
а) беренче җөмләдә «Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен өстәргә;
б) икенче җөмләдә татарча текст үзгәрешсез кала;

2) 2 статьяның беренче өлешендә «Татарстан Республикасы Конституциясенә» сүзләреннән соң «, федераль конституциячел законнарга» сүзләрен өстәргә;

3) 3 статьяның өченче өлешендә «дәүләт һәм җәмәгать органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнары һәм оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

4) 6 статьяның икенче өлешендә «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен өстәргә;

5) 8 статьяда:
а) түбәндәге эчтәлекле яңа алтынчы абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның Президиумы йөкләмәсе буенча яисә үз инициативасы белән үз карамагындагы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы законнарына мониторинг үткәрү;»;

б) алтынчы – унынчы абзацларны тиешенчә җиденче – унберенче абзацлар дип санарга;

6) 14 статьяда:

а) икенче өлештә «башка» сүзеннән соң «аеруча» сүзен өстәргә;

б) өченче өлештә «, предприятиеләрдән, учреждениеләрдән» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 15 статьяның беренче өлешендә «эше» сүзен «эшләре» сүзенә алмаштырырга;

8) 18 статьяда «предприятиеләр, учреждениеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 19 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Аерым мәсьәләләрне әзерләү өчен комитет Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структур бүлекчәләре белгечләреннән, шулай ук Татарстан Республикасы министрлыклары, Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары, башка дәүләт органнары һәм иҗтимагый берләшмәләр, фәнни оешмалар вәкилләреннән, башка белгечләрдән эшче төркемнәр төзергә мөмкин.»;

10) 20 статьяның өченче өлешендә «, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең» сүзләрен төшереп калдырырга;

11) 21 статьяда «һәм җәмәгать» сүзләрен төшереп калдырырга;

12) 22 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**22 статья**. Депутат эшчәнлеген төп эшчәнлегеннән аерылмыйча башкаручы комитет әгъзаларына үз вәкаләтләрен башкару өчен айга барлыгы алты эш көненнән дә артмаган чорга эш урынын (вазыйфасын) саклап калу гарантияләнә.»;

13) 29 статьяның беренче өлешендә «җәмәгать оешмалары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

14) 30 статьяда:

а) алтынчы абзацта «дәүләт һәм җәмәгать органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнары һәм оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

б) сигезенче абзацта «җәмәгать оешмалары» сүзләрен «оешмалар» сүзенә алмаштырырга;

в) унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«комитет карарларының үтәлеше турында, шулай ук комитетка кергән барлык документлар турында комитет әгъзаларына хәбәр итә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын аның үтенече буенча шул документларның күчермәләре белән тәэмин итә;»;

15) 32 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комитетларның уртак утырышларында кабул ителгән карарлар һәр комитет тарафыннан аерым әзерләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 03 март
№ 4-ТРЗ